# Дубайда Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормышына багышланган иң авыр китап күрсәтелде



Дубайда Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормышына багышланган 1 тонна авырлыктагы китап тәкъдим ителде. Аның биеклеге - 5 метр, киңлеге - 4 метр. Мәдәни һәм дини кыйммәткә ия булган әлеге җыентык Гиннесның Рекордлар китабына кертелгән.

Дөньядагы иң зур ислам китабын Берләшкән Гарәп Әмирлекләре финанс министры һәм Дубай хакиме урынбасары, шәех Һәмдан бин Рәшит Әл-Мәктүм Галиҗәнабләре тәкъдим кылды.

Әлеге тантанада илнең җитәкчеләре, дипломатлар, эшкуарлар, галимнәр һәм ММЧ вәкилләре катнашты. "Бу - Мөхәммәд" дигән китапта Пәйгамбәрнең тормыш юлы бәян ителә һәм әлеге диннең халыкара мәйданда тоткан урыны турында сөйләнелә. Китапның максаты - теләге булган һәркемне ислам дине һәм мөселманнар тормышы белән якыннан таныштыру.

Шәех Һәмдан инде 50 мең китапны бастырып чыгаруга заказ биргән. Алар төрле оешмаларга, шул исәптән, чит төбәкләрдәге җәмгыятьләргә җибәреләчәк.

■ Кыйсса

# «ӘТИ МИНЕМ БАЙЛЫГЫМНЫ АЛДЫ»

Бәхетле дәвердә берәү сөекле Пәйгамбәребез (с.г.с.) янына килеп, әтисенә зарлана, аңа шикаять итә: "Я, Рәсүлүллаһ! Әтием минем байлыгым - малымны алды", - ди.

Рәсүлүллаһ Әкрәм (с.г.с.) "Бар әтиең белән кил!" - дип боера.

Бу кеше китә һәм бераздан әтисе белән бергә килеп җитә.

Рәсүлүллаһ Әкрәм (с.г.с.) бу атага: "Улың байлыгы - малы хакында синнән зарлана, шикаять итә. Әти байлыгымны алып тотынды, дип әйтә", - ди.

Әтисе: "Я, Рәсүлүллаһ! Аның байлыгын бик аз гына микъдарда көнкүрешебез өчен, анасы, сеңлесе һәм үзем өчен сарыф иттем, файдаландым", - дип җавап бирә.

Рәсүлүллаһ (с.г.с.) үзенә килгән вәхи белән бу атаның күңеленнән кичергән хисләрен ап-ачык күргәндәй була. Чөнки ата күңелендә баласы өчен әрнеш, җан ачысы тоела, аның күңеленә хикәяләр килә.

Рәсүлүллаһ Әкрам (с.г.с.) егетнең әтисенә: "Шушы хәлдә эчеңдәге уйларыңны безгә дә ишеттерсәң иде", - дип боера.

Әтисе болай сөйли: "Улым, балам, син әниеңнән бик кечкенә булып, бернинди байлыксыз дөньяга килдең. Үсеп җиткәнгә кадәр күп еллар дәвамендә ихтыяҗларыңның барысын да мин үземә йөкләдем. Бәләкәй чагыңда чирләп киттең. Ул төннәрдәге кайгы-хәсрәттән таңга кадәр күзләремә һич йокы кермәде. Синең елавыңнан йөрәгем сызлап, күзләремнән яшьләр түгелде.

Хәзер син, әй өметсез бала, минем зәгыйфьлегемне, картлыгымны һич аңламыйсың. Үсеп җиттең, яшең дә, куәтең дә артты, бүгенгә кадәр минем тапканнарымның барысын да тик үзеңнеке кебек тоеп яшәдең. Инде миңа бу кадәр катылык, яманлык, дошманлык күзе белән карыйсың. Миндәге булган аталык хакына, бер күршенең күршесенә булган ярдәме кадәр дә үзең белеп хөрмәт-игътибар күрсәтмәдең...".

Бу сүзләрне сөйләгән ата кешенең күзләре яшь белән тула.

Һәм Рәсүлүллаһ Әкрәм (с.г.с.) әфәндебез бөтен өммәтләренә нәсыйхәт итеп шушы Хәдис Шәрифне боера: "Әй яшь егет, син дә, байлыгың дә әтиеңнеке!"

**Ачыклама:**

Әй Хак юлчысы! Гыйбрәт алу иң элек бәхет-сәгадәт юлчылары өчен мөмкиндер. Бу Хәдистән гыйбрәт алмаган мөселманнар, бер атадан биш-алты угыл булып та, бер атаны карамыйлар, аның ихтыяҗларын үтәмиләр. Ата ялгыз башына биш, хәтта ун баланы карый, аларның һәр ихтыяҗларын тулы, кәнәгать итә, ләкин бу угыллар бердәнбер аталарын карамыйлар, аның картлык көнендәге ихтыяҗларын үтәмиләр.

Ата-анага каты булу, аларны карамау, аларның сүзләрен тыңламау иң бөек гөнаһларның берседер. Аллаһыга каршы кылынган гөнаһлардан соң килгән бер гөнаһтыр бу.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) бер Хәдис Шәрифендә: "Ата-ана ризалыгы - Аллаһ ризалыгыдыр, ата-ана ачулануы - Аллаһ ачулануыдыр", - дип боера.

Бу дини хикәяләр китабының бик күп урыннарында әйтелгән кебек, мондый гөнаһларның гафуы юк. Ул кешене җәһәннәмнең иң хәтәр газап почмагына илтер.

Бер бала ата-анасының кадерен белмәсә, аларның туклану мәсьәләрен карамаса, ихтыяҗларын җиренә җиткерү өчен гайрәт күрсәтмәсә, алар өчен биш вакытта хәер-дога итмәсә, бу бала җәһәннәмгә утын булудан башка нәрсәгә ярамас.

Бер кеше ата-анасын рәнҗетсә, көчәндерсә, аның дога һәм гыйбадәтләре кабул булмаган кебек, имнсыз үлүенә сәбәп булыр.

Хатыны аркасында ата-анасын кәмсеткән, хатын сүзенә карап аларны рәнҗеткән, күңелләрен кырган балаларга ләгънәт булган.

Аллаһының ләгънәт капкасына муенын керткән адәм дөнья вә ахирәттә хозур вә сәгадәт йөзен күрмәс.

Бәгъзе адәмнәр, ата-анасына фитыр зәкәте белән ярдәм итәргә тотынган булалар. Ата-анага зәкәт бирелми. Алар - синең җәннәтеңдер. Әйе, әгәр аларны риза итсәң, аларның догасын ала алсаң, алар - синең җәннәтеңдер. Һәм җәһәннәмеңдер, әгәр аларны карамасаң, рәнҗетсәң.

Пәйгамбәребез (с.г.с.): "Алар яки ата-аналар, синең җәннәтең яисә җәһәннәмеңдер", - дип боера.

Бәгъзе тар күңелле адәмнәр бардыр ки (беләбез һәм күреп таныйбыз аларны), үз ата-аналарына басым ясыйлар, кысалар, үзләре шуны аңламыйлар, шуңа игътибар итмиләр. Ә инде башка берәүләр балаларның ата-анасына бер хөрмәтсезлек вә җәберләүләрен күрсә, тойса - кайгыралар, әзгәләнәләр. "Ярамый! Кара башкаларга!" - диләр. Бәлки син дә шундый ук гөнаһ үкенечләре эчендәсеңдер, я?!



## КАДЕР КИЧЕ

- Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) галәйһиссәләмнән хатыны Айшә (Радый Аллаһу анһә): "Кадер кичне нинди дога кылу хәерлерәк?", - дип сораган. Пәйгамбәребез (с.г.с.): "Аллаһуммә иннәкә тухибуль афуә фә афуанни", - дип җавап биргән.

Доганың тәрҗемәсе: ***"Йә Аллаһым! Син гафу итүче, гафу итүне яратасың. Гафу ит мине".***

- Пәйгамбәр Мөхәммәд (с.г.с.) Рамазан аеның соңгы ун кичәсендәге төннәрендә намазлар укып, догалар кылып уздыра булган.

- "Кем булса чын иман белән һәм савапка өметләнеп "кадер кичне" догада вә гыйбадәттә уздырса кылган гөнаһлары гафу ителер", - дигән.

Пәйгамбәр (с.г.с.) әйткән: "Кем Рамазан аенда алдавыннан вә ялган таныклык бирүеннән туктамаса, юкка үзен газәп күрсәтеп ач тотмасын", - дигән.

| Өфөлә намаҙ ваҡыты | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шәүүәл 2012 миләди йыл 1433 һижри йыл. | | | | | | | | | |
| Шәүүәл | Аҙна көндәре | Август, Сентябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығыу | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы | |

| Шәүүәл | Аҙна көндәре | Август, Сентябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14 | Шәмбе | 1 | 5.55 | 7.25 | 14.30 | 19.35 | 21.05 | 22.35 |
| 15 | Йәкшәмбе | 2 | 5.57 | 7.27 | 14.30 | 19.33 | 21.03 | 22.33 |
| 16 | Дүшәмбе | 3 | 5.58 | 7.18 | 14.30 | 19.30 | 21.00 | 22.30 |
| 17 | Шишәмбе | 4 | 6.00 | 7.30 | 14.30 | 19.28 | 20.58 | 22.28 |
| 18 | Шаршамбы | 5 | 6.02 | 7.32 | 14.30 | 19.25 | 20.55 | 22.25 |
| 19 | Кесе йома | 6 | 6.04 | 7.34 | 14.30 | 19.23 | 20.53 | 22.23 |
| 20 | Йома | 7 | 6.06 | 7.36 | 14.30 | 19.20 | 20.50 | 22.20 |
| 21 | Шәмбе | 8 | 6.08 | 7.38 | 14.30 | 19.18 | 20.48 | 22.18 |
| 22 | Йәкшәмбе | 9 | 6.09 | 7.39 | 14.30 | 19.15 | 20.45 | 22.15 |
| 23 | Дүшәмбе | 10 | 6.11 | 7.41 | 14.30 | 19.13 | 20.43 | 22.13 |
| 24 | Шишәмбе | 11 | 6.13 | 7.43 | 14.30 | 19.10 | 20.40 | 22.10 |
| 25 | Шаршамбы | 12 | 6.15 | 7.45 | 14.30 | 19.08 | 20.38 | 22.08 |
| 26 | Кесе йома | 13 | 6.17 | 7.47 | 14.30 | 19.05 | 20.35 | 22.05 |
| 27 | Йома | 14 | 6.19 | 7.49 | 14.30 | 19.03 | 20.33 | 22.03 |
| 28 | Шәмбе | 15 | 6.20 | 7.50 | 14.30 | 19.00 | 20.30 | 22.00 |
| 29 | Йәкшәмбе | 16 | 6.22 | 7.52 | 14.30 | 18.58 | 20.28 | 21.58 |
| 1 | Дүшәмбе | 17 | 6.24 | 7.54 | 14.30 | 18.55 | 20.25 | 21.55 |
| 2 | Шишәмбе | 18 | 6.26 | 7.56 | 14.30 | 18.53 | 20.23 | 21.53 |
| 3 | Шаршамбы | 19 | 6.28 | 7.58 | 14.30 | 18.50 | 20.20 | 21.50 |
| 4 | Кесе йома | 20 | 6.30 | 8.00 | 14.30 | 18.47 | 20.17 | 21.47 |
| 5 | Йома | 21 | 6.32 | 8.02 | 14.30 | 18.45 | 20.15 | 21.45 |
| 6 | Шәмбе | 22 | 6.33 | 8.03 | 14.30 | 18.42 | 20.12 | 21.42 |
| 7 | Йәкшәмбе | 23 | 6.35 | 8.05 | 14.30 | 18.40 | 20.10 | 21.40 |
| 8 | Дүшәмбе | 24 | 6.37 | 8.07 | 14.30 | 18.37 | 20.07 | 21.37 |
| 9 | Шишәмбе | 25 | 6.39 | 8.09 | 14.30 | 18.35 | 20.05 | 21.35 |
| 10 | Шаршамбы | 26 | 6.41 | 8.11 | 14.30 | 18.32 | 20.02 | 21.32 |
| 11 | Кесе йома | 27 | 6.43 | 8.13 | 14.30 | 18.30 | 20.00 | 21.30 |
| 12 | Йома | 28 | 6.45 | 8.15 | 14.30 | 18.27 | 19.57 | 21.27 |
| 13 | Шәмбе | 29 | 6.47 | 8.17 | 14.30 | 18.25 | 19.55 | 21.25 |
| 14 | Йәкшәмбе | 30 | 6.48 | 8.18 | 14.30 | 18.22 | 19.52 | 21.22 |

# ГЫЙЛЕМ ӨЙРӘНҮНЕҢ ФАЙДАСЫ

Солтан Мәхмүд заманында итчеләрдән берәүне солтан янына китерделәр. Бу итче каршына солтан Мәхмүд бер сарык китертте. Әйтте:

- Әй итче! Бу сарыктан күпме ит булыр, күпме май булыр, - диде.

Итче сарыкны тотып карады, әйтте:

- Фәләнчә кадәр ит, фәләнчә кадәр май булыр.

Шуннан соң сарыкны суйдылар, итче әйткәнчә булды: бер мыскал артык һәм бер мыскал ким булмады. Солтан моны күреп гаҗәпкә калды.

Янә сорады:

- Гыйлемнән берәр нәрсә беләсеңме,

Итче:

- Белмимен, - диде.

Солтан боерды:

- Бу итчене илтеп асыгыз! - диде.

Асарга алып киттеләр. Юл өстендә әлеге итченең улы очрады, мәктәптән кайтып килә иде. Әйтте:

- Минем атамны кая алып барасыз? - диде.

- Асарга алып барабыз, - диделәр.

Улы:

- Гаебе нидер? - дип сорады.

Әйттеләр:

- Солтан янында куйның ите һәм мае ничәшәр мыскал икәнен белде. Солтан аннан сорады: "Аллаһы Тәгалә сиңа шулкадәр акыл-зиһен биргән, Алланы нәрсә белән таныйсың?" - диде. Итче исә: "Танымыйм", - диде. Шул сәбәптән атаңны асарга боерды, - диделәр.



Улы әйтте:

- Атамның гаебе шул гына булса, сез бераз сабыр итеп торыгыз, мин солтанның үзен күрим, - диде.

Барды, солтанга сәлам бирде һәм әйтте:

- Минем атамны ни сәбәптән асарга әмер иттең? - диде.

Солтан:

- Аллаһы Тәгалә шулкадәр фәһем-фирасәт биргән икән үзенә, сарыкның ите-мае күпме икәнен мыскалына кадәр әйтеп бирде. Шул зиһене белән Аллаһы Тәгаләне танымый надан калган, шул сәбәптән астырам, - диде.

Итченең улы әйтте:

- И солтан! - диде, - Бу эштә атам гаепле түгел, аны мәктәпкә бирмәгән бабам гаепледер. Син менә мине күр: мин унике яшьлек сабыймын, гыйлемне миннән сора, шәригатьнең бөтен кануннарын әйтеп бирәм, - диде.

Сорадылар, малай бик күп сорауларга җавап бирде. Солтан гаҗәпләнде, бу малай хакына атасын асылудан коткарды.

Шуның кебек әгәр берәүне теге дөньяда кыямәт көнендә тәмугка китерсәләр, әгәр ул дөньяда булганда улын мәктәпкә укырга биргән булса, улы тәмуг юлына чыгып һәм каршы барып, Аллаһы Тәгаләдән үтенеп, атасын коткарып калыр.